# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXX СЕССИЯСЕ

## КАРАР №176

Мөслим авылы «14» декабрь 2023 ел

**«Мөслим муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 15 апрелендәге 95 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроле турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2001 елның 30 декабрендәге 195-ФЗ номерлы административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 15 апрелендәге 95 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (алга таба - Нигезләмә):

1.1. Мөслим муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәне 2 нче кушымта белән тулыландырырга. «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.(https://muslumovo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мөслим муниципаль районы Советының авыл хуҗалыгы, төзелеш, сәнәгать, экология һәм җирдән файдалану мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе А.Р. Хужин

Автомобиль транспортында, шәһәр җир
өсте транспортында һәм юл
хуҗалыгында муниципаль
контрольне гамәлгә ашыру турында
Нигезләмәгә 2 нче кушымта

**Мөслим муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

1. Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте транспортында һәм юл хуҗалыгында торак пункт чикләрендә һәм (яисә) бер үк җирле әһәмияттәге юлда муниципаль контроль объектында утыз календарь көн дәвамында ике һәм аннан күбрәк юл-транспорт һәлакәте.

2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша бирелгән мәгълүматлар нигезендә, контрольдә тотылган зат йөртүчеләре тарафыннан бер календарь ел дәвамында даими пассажирлар йөртү маршрутында автомобиль транспорты, шәһәр, җир транспорты белән юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу очракларының биш процентка һәм аннан да күбрәккә артуы.

3. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә бирелгән белешмәләр нигезендә юл-транспорт һәлакәтләренең саны бер календарь ел дәвамында юл инфраструктурасы объектында ике тапкырга һәм аннан да күбрәккә артуы.

4. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, контрольдә тотылган кешенең кулында булган яки файдаланган юл участогында календарь айда юл-транспорт һәлакәтләре санының биш процентка артуы (әмма ким дигәндә өч бозуга).

5.Хисап елы дәвамында юлның бер участогында яки юллар һәм урамнар киселешендә кешеләр зыян күргән яки яраланган юл шартлары белән бәйле рәвештә бер төр юл-транспорт һәлакәтенең барлыкка килүенең өч һәм аннан да күбрәк фактын ачыклау.